**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның «8» апреленнән № 20-155

Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 09 декабрендәге 16-126 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә урнашкан, 2022 елда ачык аукцион сатуларында сату юлы белән хосусыйлаштырылырга тиешле мөлкәт һәм җир кишәрлекләре исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешүләр нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль милеген хосусыйлаштыруның фараз планына (программасына) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2022 елда ачык аукционнарда сату юлы белән хосусыйлаштырылырга тиешле Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә урнашкан җир һәм мөлкәтләр исемлеген түбәндәге эчтәлектәге 6,7 пунктлар белән тулыландырырга:

| № | Милек исеме | Милекнең урнашу урыны | Хосусыйлаштыру-ның планлаштырылган вакыты |
|---|---|---|---|
| 6 | CHEVROLET NIVA, 212300-55 | Татарстан Республикасы, Яңа | 2 нче квартал 2022 ел |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | д/н Т 420 НХ116 RUS, 2014 елда чыгарылган, VIN X9L212300E0529356 | Чишмә муниципаль районы, Әдәмсә авылы, Үзәк ур., 10 йорт | |
| 7 | CHEVROLET NIVA, 212300-55 д/н Р 769 ХС 116 RUS, 2014 елда чыгарылган, VIN X9L212300F0544248 | Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Тубылгы Тау авылы, Яшьләр ур., 73 йорт | 2 нче квартал 2022 ел |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов